РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» февраль 2023 ел г. Альметьевск № 281

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт торак урынына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 декабрендәге 1927 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт торак урынына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 декабрендәге 1927 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

3.1 бүлекнең 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан соратуның электрон формасы кырларын тутыру процессында автомат рәвештә, орган (оешмалар) билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны мөрәҗәгатьнең электрон рәвешендә турыдан-туры мәгълүмати хәбәр итү юлы белән бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

23 029

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов